| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИН РАЙОНЫЙ<br>ИСПОЛНИК КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЛАР |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
"12" 04 2023 ел

**КАРАР**
№ 145

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы карары белән (2019 елның 19 августындагы 280 номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 386 номерлы, 2021 елның 2 февралендәге 62 номерлы, 2021 елның 9 апрелендәге 149 номерлы үзгәрешләр белән) расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 ноябрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 11 февралендәге 20-09/2163 номерлы хатын карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 203 номерлы карары белән (2019 елның 19 августындагы 280 номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 386 номерлы, 2021 елның 2 февралендәге 62 номерлы, 2021 елның 9 апрелендәге 149 номерлы үзгәрешләр белән) расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Компенсация алу хокукын билгеләгәндә, гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

1.2. 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булганда, компенсация билгеләү Россия Федерациясе пенсия һәм

социаль иминият фондында булган компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре турында белешмәләр нигезендә башкарыла».

1.3. 2.1 пунктның 3 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.2 пунктның 5 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.2 пунктның 7 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 3.2 пунктның 2 абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет -ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ начальнигына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов